КИТАП КАДЕРЕ
Милләтнең дәрәҗәсе югары икән, әдәбиятның да абруе зур була
> 3

МИЛЛИ ХИСЛӘР
Бөтендөнья татар конгрессының сигезенче корылтаенда хисап тоту белән генә мавыкмадылар
> 3

БОЗГА ЧЫКТЫК
Яңартылган «Ак барс» командасы Әлмәт һәм Түбән Камада ике очрашу уздырды
> 4

САЛАВАТ АЕ
Халык җырчысы быел нинди тамаша әзерләгән?
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 114 (28887) | Сишәмбе | 9 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

КЫЙММӘТЛЕ УКУ

Узган ел белән чагыштырганда быел баланы мәктәпкә әзерләү 15–20 процентка кыйммәтләнгән. Укучы мәктәпкә барганда башкалардан ким-хур булмасын өчен, уртача алганда, 10–15 мең сум акча кирәк. «ВТ» хәбәрчесе әти-әниләрнең 1 сентябрьгә ничек әзерләнгәннәрен белеште.

Берәүләр әле базарга чыгып, бәяләрне генә күзәтеп йөрсә, икенчеләр ул-кызларының букчаларын күптән тутырып куйган инде. Башка елларда әти-әниләрнең бәяләргә әллә ни исе китмәсә дә, быел чыгымнар шактый кесәгә суга, диләр. Тик шул ук вакытта, бала өчен берни дә кызганыч түгел, бары тырышып укысыннар гына, дип тә куялар.

Беренче сыйныфка баручылар өчен портфель, кирәкле җыелма бәясе 7,5 мең сум тора. Мәктәп формасы, аяк киеме 20–30 процентка кыйммәтләнгән. Узган ел малайларны мәктәпкә әзерләү кызларга караганда 5 мең сумга арзангарак төшкән. Казандагы «Успех» тегү цехында да бәяләр күтәрелүне кире какмадылар. Директорлары Илсөяр Нәҗмиева белдергәнчә, чикләүләр кертелгәч, бәяләр арткан. Тик бездә башкаларга караганда әйбер арзанрак әле, ди.

– Быел вазгыять җиңел түгел. Без тукыманы Төркиядән кайтартабыз. Күпмегә артканын әлегә санамадык, әмма бәяләр артты. Элек кайтарылган тукымалардан тегелгән киемнәр арзанрак, әлбәттә. Яз көне заказ бирүчеләр отты, бәяләр түбәнрәк иде. Август – бәяләр күтәрелгән чак. Май аенда сарафан 2000–2200 сум торса, хәзер 500–600 сумга кыйммәтрәк. Башка әйберләрдә дә чыгымнар шул чама сизелә. Зуррак сыйныф укучылары өчен мәктәп формасын 3500 сумга алырга була. Итәк, күлмәк өчен өстәмә түләргә кирәк. Төсләрен мәктәпләр үзләре сайлый. Теләккә килгәндә, югары сыйныфта укучы кызларның быел чалбар, озын жакет кияселәре килә, – ди Илсөяр Нәҗмиева.

Арча районында яшәүче Зилә һәм Дамир Гайфуллиннарның игезәк уллары Әскәр белән Әмир быел беренче тапкыр мәктәпкә бара. Аларга яхшы белем бирү өчен, авылдан шәһәргә күченеп килергә җыеналар. Кече уллары Даниярга – 6 яшь, ул әлегә бакчага йөри.

БАЛАЛАР КИЕМНӘРЕ БӘЯЛӘРЕ (СУМНАРДА)

Сарафан – 1700–3000
Күлмәк –1600
Итәк –1700
Чалбар –1600–2000
Жилет – 2000
Аяк киеме – 800–1500
Ортопедик букча – 4500–5000
Гади букча – 1000–1200

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Шәһәрдә шәһәрчә кирәк. Башкалардан ким-хур булмасыннар дип, бер ел алдан ук 100 мең сум акчаны хәстәрләп куйдым. Дөрес, әлегә аның кадәр үк тотылмады, тик уку елы дәвамында кирәге чыгуы бар, – ди шәфкать туташы булып эшләүче Зилә.

Бәяләр күтәрелгәнче дәфтәр, каләм, букча, уку кирәк-яракларын алдан ук сатып алган ул. «Барган саен кибеттә мең сум калдырдым инде. Шуңа күрә укырга баруның күпмегә төшкәнен төгәл генә әйтә алмыйм. Форманы махсус тектердек. Костюм, жилет, галстук барысы бергә 6 мең суга төште. Күлмәкне аерым алдык. Берсе 1000 сум тора. Безнекеләргә дүртәү кирәк. Әле менә интернет кибетләрдән бәяләрне караштырып утырам. Арзанракка табарга була икән. Әйтик, ташлама белән бер пар аяк киемен 1200 сумга да алырга мөмкин. Бәяләр артык кыйммәт сыман тоелмады миңа. Әйбәт укысыннар гына, акча дип торып булмый. Егетләремнең укырга барасы килә инде», – ди өч ул тәрбияләүче ана.

Гөлия Хамед гаиләсенең мәшәкате тагын да зуррак, аларга быел дүрт баланы мәктәпкә әзерләргә кирәк. Әлегә кибет-базарларда бәяләр белән кызыксынып йөрүләре. Гөлия әйтүенчә, бер баланы мәктәпкә әзерләү 35–40 мең сумга төшәчәк. Мәктәп кушкан исемлек буенча шулай чыга икән. Олы кызлары Мәликәгә – 15 яшь. Зәйнәп исә быел 1 нче сыйныфка җыена. Укый-яза белә икән инде. 100 дәфтәрдән башка берни дә сатып алмаган әле алар.

– Исемлек бик озын. Иремә, фәлән кадәр акча кирәк, дип әйттем инде. Киләсе атнада кибетләргә чыга башларбыз. Мәктәп биргән исемлек буенча бәяләр бик кыйммәткә төшә. Бу суммага мин әле көзге, кышкы өс-башны да керттем. Киемнәрнең хаклары бик нык артты бит. Башка елны мәктәпкә җыену өчен бер балага дәүләт 10 мең сум бирә иде. Быел хәбәр юк, бирмәсләрме дип көтәбез, һич югы, мәктәп формасына ярап куяр иде. Акчасы табылыр, мәшәкать түгел бу. Сөенеч итеп кенә кабул итәбез. Балаларның үзләренә дә кызык, – ди Гөлия. – Кайбер киемнәр апаларыннан сеңелләренә кала. Әмма күлмәкләр бик тиз туза. Көн саен юарга кирәк. Парталар чиста түгел, шуңа күрә мәктәптән пычранып кайталар. Тузан сөрттерегез, идән юсыннар, дип тә әйтеп карадык. «Сез нәрсә, балаларга хәзер урындык та күтәрергә ярамый», – диде укытучыбыз.

Ахыры 2 нче биттә >

Хәтәр су

Ел башыннан бирле Татарстан сулыкларында 70 куркыныч очрак килеп чыккан. 57 кеше, шул исәптән 8 бала һәлак булган. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе мәгълүматларына караганда, коену сезоны башланганнан бирле 50 кешене, шул исәптән 3 баланы суга батудан коткара алганнар. Моңа кадәр хәбәр ителгәнчә, Татарстанда 1 июльдән 51 кеше, шул исәптән 8 бала баткан. Шушы чорда сулыкларда барлыгы алты үлем-җитем очрагы теркәлгән.

Белгечләр әйтүенчә, суга батуның төп сәбәпләре – тиешенчә җиһазланмаган урында коену һәм сәламәтлек начараеп китү сәбәпле, суга егылу.

Урманнарга кермәгән

Ел башыннан Татарстанда корыган үлән янып китүнең 457 очрагы (барлыгы 15,7068 гектар мәйданда) теркәлгән. Быел урманнарны вертолеттан карап-тикшереп йөрү сәгатьләре 1,5 тапкыр арттырылган. Узган елда Лениногорск һәм Әлмәт районнарында ике зур янгын булган. Ул чагында 25 гектардан артыграк мәйданда урман янган. Янгын тәүлек эчендә сүндерелгән. Быел республика урманнарында янгын чыгу очраклары юк.

Исегезгә төшерәбез: Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 14 майда урман янгыннарын кисәтү чараларын көчәйтергә кушты. Ул Гадәттән тыш хәлләр һәм Урман хуҗалыгы министрлыкларының, муниципалитетларның янгын куркынычын аерым контрольдә тотарга тиешлеген белдерде.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министры Александр Чуприян кипкән үләнне яндыруны тыярга тәкъдим итте.

10 сентябрьдән башлана

Казанда 10 сентябрьдән көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре башлана. Бу сезонда сәүдә урыннары артачак: хәзерге вакытта Юдино бистәсенең Революция урамында чатырлы мәйданчык төзелә. Моннан тыш, Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илдар Шакиров белдергәнчә, фермер продуктлары белән мобиль сәүдәне үстерү күздә тотыла.

Быел гыйнвар аеннан бирле Кулланучылар базары комитеты һәр көн саен социаль әһәмиятле азык-төлек бәяләрен күзәтә. «Берара шикәр комына, башлы суган, үсемлек маена бәяләр кисәк кенә күтәрелеп алды. Сәбәбе ясалма тудырылган ихтыяҗга һәм товарны җитештерүчедән сатып алу бәясе артуга бәйле булды», – дип искә төшерде Шакиров. Аның сүзләренә караганда, бәяләрне йөгәнләү өчен товар җибәрүчеләр һәм сатучылар белән сөйләшүләр алып барылган. Язгы авыл хуҗалыгы ярминкәләре дә бәя үсүне тоткарлауга ярдәм иткән. Алты ярминкә көнендә шәһәр халкы барлыгы 266 миллион сумлык товар сатып алган. Шикәр комы туплап куелган запастан сатылган. Бу исә товарга кытлыкны киметү мөмкинлеге биргән.

Хәзерге вакытта кибетләргә азык-төлек бернинди өзеклексез китерелә. Сәүдә предприятиеләре гадәттәгечә эшли. Казан башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гаффаров сүзләренә караганда, азык-төлек складлары тулы.

Август кызуы сүрелми

Татарстанда тәүлеклек уртача температура нормадан 4–5 градуска югарырак. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, узган елларда республикада +28…+32 градус булган. Һава көннән-көн кыза, ди синоптиклар. Аларның әйтүенчә, эсселек антициклон хөкем сөрүгә бәйле.

Гидрометеоүзәк белгечләре искә төшереп үткәнчә, һава торышы күзәтелгән вакыт кысасында бездә иң югары температура 2010 ел җәенең беренче декадасында теркәлгән. Ул чагында эсселек +35…+42 градуска җиткән. Синоптиклар фаразына караганда, атнаның икенче яртысында көннәр бераз гына сүрелә башлаячак. Атна ахырында көндезге һава температурасы +28 градустан артмаячак. Бу араларда +33. Төнлә температура +14…+20 градус тәшкил итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яшәеш

Ярдәм булырмы?

Август аена кердек. Ике ел рәттән, бу вакытта әти-әниләр мәктәптә укучы һәр баласы өчен унар мең сум күләмендә пособие алган иде. 2020 елда Татарстанда дәүләт 700 мең балага ярдәм күрсәткән.

6 яше тулмаган 54 мең балага өч ай дәвамында 5әр мең сум түләнде, калган 640 мең сабыйның әти-әнисе унар мең сум күләмендә акча алды. Узган ел исә 8 яшьтән 17 яшькәчә 563 мең бала гаилә бюджетын унар мең сумга калынайтты.

Билгеле булганча, әлеге ярдәм Россия Президенты Владимир Путин карары белән бирелде. Пандемия вакытында күп кенә кешеләрнең эшсез калуы, тормыш шартлары катлаулану сәбәпле, бу акча баланы мәктәпкә әзерләү өчен бик тә урынлы булды.

Халык тагын көтә. Быел булырмы – бу хакта редакциягә шалтыратып та сорыйлар. Казанда яшәүче Ләйсән Мортазина узган ел бу акчаны 4 баласына да алган. Быел да өметләнә икән.

– Дәүләттән килгән унар мең сум акчага рәхәтләнеп яшәп була иде. Һәр баланың үзенә җитәрлек иде ул. Быел да булыр дип көттем. Халык арасында да шундый сүзләр йөри, – ди ул.

Белештек. Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат үзәге җитәкчесе Альбина Никандорова сүзләренчә, аларда балаларга өстәмә акча бирелү хакында бернинди мәгълүмат юк.

– Без бу хакта белмибез. Биреләсе булса, Пенсия фонды хәбәрдар булыр иде. Мөгаен, кешеләр бу акчаны башка пособие белән бутыйдыр, – диде ул.

Ә пособиеләр чыннан да түләнә. Әмма һәркемгә түгел. 1 майдан гамәлгә кертелгән акчаны биргәнче, гаиләнең матди хәле төрле яктан тикшерелә. Әгәр гаиләнең уртача айлык кереме республикада җан башына билгеләнгән яшәү минимумыннан, ягъни 10756 сумнан ким икән, мондый ярдәмгә өметләнә алалар. Пособие күләме дә төрлечә булырга мөмкин. Анысы гаиләнең матди хәленә карап билгеләнә. Берәүләргә – яшәү минимумының яртысы, икенчеләргә – 75 проценты күләмендә, өченчеләргә тулысынча түләргә мөмкиннәр. Гаиләдә 8–17 яшьләр арасында берничә бала бар икән, мохтаҗ дип табылган очракта, бу пособие ай саен аларның һәрберсенә түләнәчәк. Бер гариза белән ярдәмне бер елга билгелиләр. Аннан соң документларны яңартырга кирәк булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Наил МӘҺДИЕВ, Чаллы мэры:

Мондый фаҗигале очраклар өлкәннәрнең балаларын күзәтеп торырга тиешлеге турында уйларга мәҗбүр итәргә тиеш. Баланы югалтырга бер саксыз адым да җитә. Аннары ничек яшәргә? Бу хакта сөйләве бик авыр, әмма сөйләргә кирәк! Без, өлкәннәр, барыбыз да гаепле.

(Чаллыда ике баланың үлеменә китергән янгын турында)

ТАТАРСТАНДА – УРЫП-ҖЫЮ

8 августка булган мәгълүматларга караганда, республика кырларыннан 789208 тонна уңыш җыеп алынган. Урып-җыю эшләре 195476 гектарда башкарылган. Уртача уңыш гектарыннан 40,4 центнерны тәшкил итә.

ИҢ ЗУР УҢЫШ КАЙДА?

Район	Суктырып алынган (т)	Уртача уңыш (ц/га)
Тәтеш	64727	55,0
Яңа Чишмә	50241	50,6
Буа	44478	41,2
Нурлат	42829	38,4
Минзәлә	37349	50,2
Аксубай	34354	40,2
Актаныш	33660	37,2
Чистай	32980	40,3
Зәй	31454	50,1
Алексеевск	31048	33,6



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АЗЫК-ТӨЛЕК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ҺӘМ КОНФЛИКТЛАР СЕРИЯСЕ

Үткән атнада дөньякүләм афәтләр спирале бөтерелүен дәвам итте. Кытай Тайвань тирәсендә хәрби өйрәнүләрне тагын бер көнгә озайтты. Бу уңайдан Япониянең Пекиндагы элекке хәрби атташесе Бондзи Охара без «Ватаным Татарстан»да китергән фикерне әйтте: «Кытай әлегә АКШ белән турыдан-туры бәрелештән кача, чөнки Тайваньга каршы реаль хәрби операция башларлык куәте юк», – диде. Әмма хәл киеренке. Белгечләр, Кытай 2025–2027 елларга сугышка әзер булачак, диләр. Планетаның төрле почмакларында кораллы бәрелешләр саны арта. Таулы Карабах яңадан утлы конфликт зонасына әйләнде. Азәрбайҗан кораллы көчләре берничә стратегик биеклекне кулга төшерделәр. Иң әһәмиятлесе – Буздух тавы. Азәрбайҗан Оборона министрлыгы аның алынуын ял көнне хәбәр итте. Бу тауның яулануы Таулы Карабахның төньяк-көнбатыш өлешендә Азәрбайҗан армиясе позициясенең көчәюе турында сөйли. Баку, әлбәттә, Әнкара һәм Мәскәү белән консультацияләрдән соң гына атлый бу хәлиткеч адымнарны. Әнкараның Мәскәү белән сәхнә арты килешүен дә тоемларга була.

Фәләстыйнда гыйбри – гарәп каршылыгының чираттагысы булып узды. Байтак кан коелганнан соң, Мисыр арадашлыгында утны туктату турында килешүгә ирешелде.

Дәүләтләр арасындагы кораллы бәрелешләрдән тыш илләрнең үз эчендә дә халык күтәрелешләре саны арта. Һиндстанда 330дан артык оппозицион лидер кулга алынды. Алар арасында 65 парламент әгъзасы бар. Көньяк Африкада демонстрация вакытында кан коелды. Бангладештан да ике демонстрант үтерелде дигән хәбәр килде. Мадагаскарда электр энергиясенең даими өзелүләренә һәм азык-төлеккә, ягулыкка бәяләр күтәрелүгә каршы стихияле халык күтәрелешләре башланды.

Конфликтларның барысының да артында икътисади кризис ята. Бөтендөнья банкы иң көчле азык-төлек инфляциясенә дучар ителгән илләрнең исемлеген китерде. Ливанда – 332, Зимбабведа – 255, Венесуэлада – 155, Төркиядә – 94; Иранда – 86, Шри-Ланкада – 80, Аргентинада – 66 процент. Дөнья икътисады түбәнгә тәгәрәүне тизләтә. Рәсми рәвештә рецессия дигән сүзне әйтергә курыксалар да, ул бара инде. Үткән атнада нефтькә бәяләрнең йөз доллардан түбәнгәрәк китүе Җир шары күләмендә җитештерүнең кимүен дәлилли. Япониядән: «Илдә нефтькә бәяләр түбәнәюен шомланып күзәтәләр, бу дөнья икътисадының темплары кимү, хәтта түбәнәю турында сөйли», – дигән хәбәр килде. Хәзерге икътисади түнтәрелеш дөньякүләм зур хәрби конфликтның алшарты булып тора. Державалар хәрби бәрелешләргә мөмкин кадәр күбрәк дәүләтләрне тартып кертергә тырышалар. Тайвань тирәсендә өйрәнүләр вакытында Кытай Япониянең эксклюзив икътисади зонасына биш ракета җибәрде. Дөрес, алар диңгезгә төштеләр һәм берниндиi дә зыян салмадылар. Әмма япон газетасы «Санкэй», Тайвань хәрбиләренең мәгълүматына таянып, Пекин зур булмаган япон утравы Ёнагунига һөҗүм имитацияләде дип язды. Утрауда японнарның радар базасы урнашкан. Чиннар һөҗүмдә 500 километр ераклыкка оча торган «Дунфэн-11А» баллистик ракеталарын, мең километрга кадәр оча торган «Дунфэн-16» ракеталарын һәм «PHL-6» залп уты ачучы системаларны (АКШ ХИМАРСларының төрдәше) кулланды. Күрәбез, киеренкелекне ясалма рәвештә көчәйтергә телиләр. Шулай булмый ни: Bloomberg Кытайда кредит кризисы яңа фазага күчте, дип яза. Хәзер иң зур China Vanke компаниясе өстендә дефолт кылычы эленеп тора.

Россиядә

ТӨРКИЯ – РОССИЯ КИЛЕШҮЕ

Россия һәм Төркия лидерларының күзгә-күз очрашуы без яшәгән ил өчен үткән атнаның иң әһәмиятле яңалыгы булгандыр, мөгаен. Искә төшерик әле: март башында дәһшәтле санкцияләр кертелеп ярымшок хәлендә калганда, без «Ватаным Татарстан»да: «Барлык илләр дә безгә ишекләрен шап итеп ябып бетермәделәр. Төркия үзара хезмәттәшлек ягында. Технологик яктан кызу темплар белән үсеп баручы бу ил Көнбатыш сатудан баш тарткан кайбер технологик продуктлар белән безне тәэмин итә алыр иде», – дип яздык. Путин белән Әрдоган очрашуында ике ил арасында сәүдә әйләнешен 100 миллиард долларга җиткерү турындагы килешүгә ирешү безнең тышкы сәясәт юнәлеше векторын дөрес чамалавыбыз турында сөйли. Төркия – Россия аркадашлыгының үсүенә Көнбатышта да игътибар итәләр. «Көнбатыш илләрендә Төркиянең Россия белән элемтәләре ныгу уңаеннан шом арта», – дип яза британ газетасы Financial Times. «Вашингтон пост» та Россиянең Төркия ярдәмендә Көнбатыш санкцияләрен әйләнеп узарга тырышуын игътибарга ала. Америкалылар язуына караганда, Россия, үз нефтен сату өчен, Төркиянең нефть эшкәртү заводларын сатып алырга җыена икән. Көнбатыш чиновникларының берсе: «Әгәр Төркия, Россия белән килешүләрен үтәп, хезмәттәшлекне арттырса, халыкара оешмалар үз банкларыннан һәм корпорацияләреннән төрек банкларындагы акчаларын чыгаруны таләп итәргә мөмкиннәр», – дигән фикер белдерә. Әмма Көнбатышның мәртәбәле башка түрәләре андый ихтималлыкны кире кага.

Төркиянең үз матбугаты Сочидагы саммитка төп урынны бирде. Хәтта Фәләстыйн фаҗигасен яктырту да икенче планга калдырылды. Хөкүмәт яклы Yeni Şafak газетасы Путинның: «Европа Төркиягә рәхмәтле булырга тиеш», – дигән сүзләрен төп язмасының исеме итте. Akşam газетасы да беренче биткә шул сүзләрне чыгарды. Türkiye газетасы, төп тема итеп, газга сумнарда түләүне алды.

Россия белән хезмәттәшлектән баш тартып, Көнбатыш илләре зур югалту кичерә. Сүз углеводородлар турында гына бармый. Карандашлар һәм канцелярия товарлары җитештерүче иң өлкән дөньякүләм компанияләрнең берсе –Koh-i-Noor Hardtmuth чех компаниясе үз продукциясенең кимендә 20 процентка кадәр кыйммәтләнүен хәбәр итә. «Элек Россиядән сатып алган агачны бүтән алырга ярамый. Аны Россиядән Кытай сатып ала да, без, Кытайдан алып, океаннар аша ташыйбыз», – ди Seznam Zpravy басмасына компаниянең хуҗасы Властислав Бржиза. Көнбатыш белән конфликт Россия өчен дә зыянлы, билгеле. Төрекләр белән аркадашлык бу зыянны берникадәр йомшарта.

КИТЕРЕП БИРӘЛӘР

Чиратсыз, тиз һәм уңайлы! Соңгы арада тормышыбызның алыштыргысыз өлешенә әверелеп барган маркетплейслар нәкъ менә шул сыйфатлары белән алдыра. Һаман да шул кулдан төшмәгән телефон аша җаның теләгән әйберне заказ бирәсең дә, вәссәлам! Бәяләрне чагыштырырга, үзеңә кирәкле әйберне шактый зур ташлама белән дә алырга мөмкин биредә. Өстәвенә кибетләрдәге кебек су буе чират та торасы юк!

Йортыбызның беренче катында урнашкан интернет-кибетнең товар тапшыру пунктыннан кеше өзелми. «Соңгы арада ялкаулыкка чыктым. Кирәк әйбергә телефон аша гына заказ бирәм дә товарны шушында төшәм дә алам. Йорт кирәк-яракларын, кер юу порошокларын да биредән генә алам. Көнкүреш техникасы да алып караган бар. Гадәти кибеткә азык-төлек алырга гына йөрибез хәзер», – ди Лилия. Быел беренче сыйныфка укырга керүче кызларына мәктәп кирәк-яракларының бер өлешен дә интернет-кибеттән алган алар. «Кибет бәяләре белән чагыштырып караган идем, 5 мең сум чамасы акчаны янга калдырганбыз икән», – ди күршем.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Ил күләмендә шул рәвешле акчаны янга калдырып яшәүчеләр шактый. Anketolog.ru порталы уздырган тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, соңгы өч айда Россия халкының 59 проценты өс киеме, аяк киеме белән вактөяк аксессуарларны нәкъ менә маркетплейс аша сатып алган. Биредә косметика (46 процент), көнкүреш химиясе (37 процент), көнкүреш техникасы (30 процент) алучылар да шактый.

Соңгы бер елда Россиядә үз товарын маркетплейс аша сатучылар саны да ике тапкыр арткан. Татарстанда, әйтик, ярты ел эчендә маркетплейс аша сату итүчеләр саны 37 процентка арткан. Шул рәвешле республикада үз товарын шушы юл белән сатучылар саны 31,5 меңгә җитә. Казан башкарма комитеты рәисе урынбасары Илдар Шакиров сүзләренә караганда, интернет-киңлеккә чыккан эшмәкәрләр саны буенча Татарстан Идел буе төбәкләре арасында алдынгылар рәтенә баскан.

«Бүген аларның күбесе Ozon, Wildberries, KazanExpress кебек танылган маркетплейсларда сату итә. Бездә моның өчен барлык шартлар да тудырылган. Казанда гына да 435 товар кабул итү пункты, бер меңләп товар бирү пункты эшли. Инфраструктура яхшыру сәбәпле, товарларны кайтару вакыты да кыскарды. Әйтик, 2020 елда маркетплейс аша заказ бирелгән товарны биш көн көтәсе булса, хәзер ул өч көн дигәндә килеп җитә», – ди Илдар Шакиров.

Сүз уңаеннан, Татарстан Икътисад министрлыгы һәм министрлык карамагындагы Эшкуарлыкка ярдәм фондының «Минем бизнес» үзәге илнең әйдәп баручы маркетплейсларына чыгуга һәм эшләүгә багышланган «Идеядән сатуга кадәр» исемле онлайн форумнар сериясен дәвам иттерә. Икенче форум-марафон Ozon маркетплейсы белән эшләүгә багышланачак. Ул 22 августтан 5 сентябрьгә кадәр узачак. Ике атна дәвамында анда катнашучылар сәүдә мәйданчыгында эшләүнең нечкәлекләрен өйрәнәчәк. Марафонда катнашу өчен +7 (843) 524-90-90 номеры буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Маркетплейс аша товар сатып алганда ничек алданмаска? Россия сыйфат системасы идарәсе (Роскачество) белгечләре түбәндәге киңәшләргә колак салырга өнди.
Түбән бәягә кызыкмагыз. Бер үк товарга булган бәяне берничә мәйданчыкка кереп тикшерегез. Аның хакы дистрибьютер куйган бәядән артык аерылырга тиеш түгел.
Кайтавазларны укыгыз. Маркетплейстан әйбер сатып алыр алдыннан иң элек бу товар турындагы кайтавазларны укыгыз. Алар товарның сыйфатына күзләрне ачып кына калмыйча, сатучының биредәге рейтингын да арттыра. Рейтингы зур булган сатучыдан товарны тыныч күңел белән сатып алырга мөмкин.
Урында ук тикшерегез. Товарны алганда ук тикшереп карарга онытмагыз. Маркетплейстан заказ биреп кайтарылган товарның йомарланган, ертылган, кителгән җирләре булмаска тиеш. Өстә-өстенә ябыштырылган этикеткалы товар да шик уята. Аның инде бер тапкыр ачып ябылган булуы ихтимал.
Товар өчен алдан түгел, кулга алгач кына исәп-хисап ясарга тырышыгыз. Товарны кире кайтарырга туры килсә, мәшәкате азрак булачак.
Кырыкалдарлар кулланган алымнардан хәбәрдар булыгыз. Еш кына алар маркетплейска фәлән әйбер сатуы турында игълан урнаштыра да кеше шуны алырга теләвен белдергәч, бу товарның әлегә беткәнлеген, әмма аны зур ташлама белән икенче базадан алып җибәрә алуларын хәбәр итә. Моның өчен кешенең телефон номерын сорап, картасындагы бөтен акчасын салдырып та алалар. Шуңа күрә маркетплейстан әйбер сатып алганда, сатучы белән шушы интернет-мәйданчыкта гына аралашырга кирәк.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Төбәкара хезмәттәшлекне ныгытудагы казанышлары һәм Тәтеш муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башлыгы **Сафиуллов** Рәмис Хатыйп улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы дәүләтчелеген үстерүдәге аеруча мөһим казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе **Зарипов** Айрат Ринат улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераннары: **Глухов** Валентин Андреевич; **Җәләлетдинова** Әминә Хәбибулла кызы; **Китанина** Надежда Геннадьевна; **Мусаев** Ренар Абдрахман улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Адвокатлар коллегиясе» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасының Казан шәһәре Совет районы буенча филиалы адвокаты **Анкудинова** Марина Николаевнага, Антипина Елена Борисовна Татарстан Республикасы адвокат кабинеты адвокаты **Антипина** Елена Борисовнага, Казан шәһәре Киров районының Адвокат үзәге адвокаты **Марфин** Павел Васильевичка, «Татарстан Республикасы Адвокатлар коллегиясе» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасының Чистай шәһәре буенча филиалы адвокаты **Мусин** Альберт Монир улына, Татарстан Республикасы Чаллы шәһәр суды судьясы **Сәхипов** Әгъла Гыйндулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Үлүчеләр дә, туучылар да кимегән

Статистикага ышансаң, Россиянең һәр дүртенче төбәгендә кеше саны арткан. Әмма бу бала табучыларның күплегенә генә бәйле түгел. Белгечләр күпчелек очракта сәбәп итеп миграцияне атый.

Росстат мәгълүматларына караганда, ил халкының июнь аенда табигый кимү күрсәткече 28744 кеше тәшкил иткән. Бу узган елның июнь ае күрсәткечләреннән 2,15 тапкыр кимрәк. Оешма китергән башка мәгълүматларга ышансаң, бу айда Россия буенча 111986 бала дөньяга килгән, 140730 кешенең гомере өзелгән. Гомумән, елның алты аенда илдә 635,2 мең кеше туып, 1 млн 19 мең кеше үлгән.

Татарстандагы вазгыятькә килгәндә, июнь аенда республикада 3343 кеше бакыйлыкка күчкән. Бу 2021 елгы күрсәткечтән 26,9 процентка кимрәк. Гыйнвар – июнь аралыгын карасаң, республикада 23325 кеше үлгән. Бу шулай ук былтыргы күрсәткечтән 8,6 процентка кимрәк.

Июнь аенда үлүчеләрнең 50се коронавирус аркасында бакыйлыкка күчкән. Росстат мәгълүматлары буенча, COVID-19 28 кешедә ачыкланган, ә калган 22 кешедә үлемгә китерүче төп сәбәп буларак каралган. Тик төгәл әйтү өчен, өстәмә медицина тикшеренүләре таләп ителә икән.

Үлүчеләр саны буенча Татарстан Идел буе федераль округы төбәкләре арасында дүртенче урынны алып тора. Беренче урында – Башкортстан. Июнь аенда күрше республика 3851 кешесен югалткан. Икенче-өченче урыннарда – Түбән Новгород (3527) һәм Самара (3374).

Туучылар санының да кимүе күзәтелә. 2022 елның ярты елында Татарстанда 17667 бала туган. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырып караганда, бу 10,2 процентка азрак дигән сүз.

Балалар үлеменә бәйле статистика исә үзгәргән. Республикада алты ай эчендә 56 яңа туган сабый үлгән. Былтыргы күрсәткечтән 28,2 процентка кимрәк бу. Гомумән, ил буенча 3054 бала вафат булган.

Кыйммәтле уку

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Балык Бистәсе районында яшәүче ике бала анасы Ләйсән Мингарипова балаларны мәктәпкә әзерләү шактый чыгымлы дип саный. Олы кызы 7 нче сыйныфка барса, төпчеге бакчага йөри.

– Дәфтәрләр ала башладык, форма, итәк, аяк киеме кирәк. Баштанаяк киендерәсе бар әле. Чыгымнар күп. Бер елны икесенә 25 мең сум киткән иде. Быел бәяләр тагын да күтәрелде. Пластилин, төсле карандаш, җилем, пумала, ак кәгазь… Боларга гына 2 мең сумны чыгарып саласы. Кышкы, язгы киемнәр дә кирәк бит. Без – аз керемле гаилә. Бер баламның сәламәтлегендә проблема бар. Мәктәпкә бара алмыйча, берничә ай өйдә укыганда, социаль яклау бүлеге, мәгариф бүлегеннән планшет сораган идем, ярдәм булмады. Элек 1–2 мең сум булса да бирәләр иде, хәзер анысы да юк. Дөрес, узган ел мәктәптә бушлай ашаттылар, продукциясен дә бирделәр. Анысына рәхмәт, – ди Ләйсән.

Акчаны ничек янга калдырырга?

Ләйсән ХАЛИКОВА, финанс киңәшчесе:

– Һәр кешенең – үз акча янчыгы. Мәктәпкә әзерләнүнең төгәл суммасын әйтеп булмый. Кемдер брендлы, кемдер гади кием сайлый. Тик мәктәпкә әзерләнү өчен, ким дигәндә, 10 мең сум кирәк. Моңа форма, уку әйберләре керә. Гаилә ничек кенә бай булмасын, финанс белеменә, чыгымнарны киметергә өйрәнергә тиеш. Бу баланы әйбер, акча кадерен белергә өйрәтәчәк. Беренчедән, нәрсәдер сатып алганчы, булган әйберләрегезне күздән кичереп чыгыгыз. Шуннан соң кирәклеләренең исемлеген төзегез. Әтиәниләрнең балага яхшы булсын дип, ел саен яңа әйбер сатып алуын бер дә хупламыйм. Мәсәлән, яңа пенал. Кыяфәте әйбәт булса, аңа нишләп акча сарыф итәргә? Ел буе йөреп пычранган пеналны яхшылап юып, аңа яңа төс кертергә мөмкин. Гел яңаны алу турында гына уйламагыз. Дәфтәр, каләм ише әйберләрне сезон вакытында күпләп алырга тырышмагыз. Сентябрь якынлашканда, бәяләр 2–3 тапкыр арта. Иртәрәк сатып алсагыз яхшы, бик ашыгыч булмаса, сентябрь ахырын көтегез. Бу вакытта арзанрак булачак. Ташлама күрдем дип капкынга эләгә күрмәгез, бу җәлеп итү чарасы гына булырга мөмкин. Маркетплейслардан файдалану популяр хәзер, анда ташламалар да күп. Дәфтәрне генә түгел, киемнәрне дә шуннан сатып алырга була, ошамаса кире кайтара аласыз. Бу акчаны янга калдырырга ярдәм итәчәк.

ЗАМАНА СӨТЕ

ФЕРМАДА РОБОТЛАР СЫЕР САВА

«Август-Мөслим» агрофирмасы комплексында сыерларны роботлар сава. Ашарларына да ризыкны махсус җайланма сала, асларын чистартырга да кул көче таләп ителми. Нәтиҗәсе дә яхшы: биредә тәүлегенә хәтта 70 литрга кадәр сөт бирүче сыерлар бар. Әлеге заманча ферманы без дә күреп кайттык.

Барлыгы 2400 баш сыерга исәпләнгән ферма Мөслим районының Уразмәт авылында урнашкан. Генераль директорның терлекчелек буенча урынбасары Нияз Газизуллин сөйләвенчә, фермаларның берсендә сыерларны 18 робот сава, янәшәдәгесе карусель системасы буенча эшли.

Роботлаштырылган ферманың үзенчәлеге шунда: сыерлар биредә тәүлек буе савыла.

– Малкайлар кайчан телиләр, шул вакытта савылырга барып баса. Башка вакытта тели икән ашый, тели икән су эчә яки ятып ял итеп ала. Кыскасы, үзе теләгәнчә яши. Шунлыктан сөтләре дә күп, – дип аңлатты җитәкче.

Ферма әле күптән түгел генә төзелгән. Әлеге вакытта бозаулар белән бергә барысы 3 меңнән артык терлек бар. Голштин токымлы сыерларны исә Германиядән кайтарганнар.

Безгә аңлатуларынча, бина бикбокс стилендә төзелгән. Әйтергә кирәк, мондый тәҗрибә Татарстанда беренчеләрдән булып кулланылган. Ягъни 1200 баш сыер бер түбә астында яши дигән сүз. Һәр яклап вентиляторлар эшләп торганлыктан, һава туктаусыз алышынып тора.

Күрәсең, ияләшмәгәнгәдер, үтәли җил йөреп торгач, бина эче салкынча булып тоелды безгә. Шуңа күрә Нияз Газизуллиннан: «Терлекләргә салкын түгелме соң монда?» – дип кызыксындык.

– Сыерларга менә шундый һава торышы яхшы да инде. Алар эссе яратмый. Кышын пәрдәләр ябыла һәм вентилятор алай ук суытмый, – дип аңлатты ул.

Малларның рационын да компьютер көйли. Савытка ризыкны махсус җайланма сала.

– Сыерларны савыла торган урынга тәмле ризык белән җәлеп итәбез. Башта катнаш азык сибелә. Аннан соң гына савыла. Барлык сыер да дүрт яки ике тапкыр савыла дип әйтеп булмый. Роботка кайсыдыр – өч, кайсыдыр хәтта дүрт тапкыр баса. Ләкин аннан да артмый. Сыер кирәгеннән артык керсә, робот инде аңа ризык та бирми, сөтен дә саумый.

Робот сауган арада компьютер сыерның санын, күпме сөт бирүен, майлылыгын күрсәтеп бара.

Җитәкче сүзләренчә, сыерлар тәүлегенә уртача 38 литр сөт бирә. Ләкин араларында 70 литрдан артыграк сөт биреп шаккатыручы рекордсменнары да бар икән.

– Бу бүлектә сыер савучылар эшләми. Барысын да робот башкара. Асларын чистарту өчен дә, терлекләрнең ашарларына бирү өчен дә эшче куллар кирәкми, – ди Нияз. – Шуңа күрә монда белгечләр генә эшли. Зоотехниклар, ветеринар табиблар, инженерлар. Алардан тыш бозау карауччылар бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бозаулар да заманча шартларда яши. Ягъни барысы бергә түгел, ә һәркайсы аерым читлекләргә урнашканнар.

Роботлаштырылган ферма янәшәсендә карусель системасында эшләүче ферма да бар иде. Анысы шулай ук 1200 сыерга исәпләнгән. Анда инде сөтлебикәләрне сыер савучылар көтеп тора. Карусельдә исә берьюлы 40 сыер савыла.

– Биредә сөтлебикәләрне дүрт сыер савучы карый. Көненә өч тапкыр савалар. Беренче савым иртәнге сәгать 7дә булса, соңгысы – төнге 11дә, – ди белгеч.

Аның фикеренчә, роботлар сауганда сыер күбрәк сөт бирә, чөнки сыерлар сөтне үзләре теләгән вакытта бирә. Ягъни стресс аз кичерәләр. Мәҗбүриләү юк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Мин кулыма китап алам

ӘДӘБИЯТНЫҢ ДӘРӘҖӘСЕ НИНДИ?

Менә бу сорау бик гади генә кебек тоелса да, аңа тиз генә җавап биреп булмый. Бер карасаң, дәрәҗәсе бар инде аның. Ни генә әйтсәң дә, татар әдәбияты көчле, теләсә кайсы әдәбият белән ярыша алырлык әсәрләре бар. Үзебезнекеләр аны бик үк күреп тә бетерә алмый бугай, карашлары читкә төбәлгән. Язучыга хөрмәт тә юк түгел. Һәрхәлдә, укучыларың күп, исемең ишетелеп тора икән, бөтенесе дә сиңа хөрмәт белән карый. Ләкин бөтен сулышы акчага корылган җәмгыятьтә кешенең һәм һөнәрнең дәрәҗәсе матди керем белән билгеләнә бугай.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Менә мин бер мәлне кечкенә сарай төзеттем. Ике шабашник килеп, өч көн эшләделәр дә минем өч ай буена язган повестьтан килгән гонорарны алып киттеләр. Язучы өч айда эшләгән акчаны шабашник өч көндә эшли! Кайсының дәрәҗәсе зуррак?

Дөньяда, АКШта һәм Европада аның дәрәҗәсе бик зур. Аларда, мәсәлән, әдәби бәйгеләрнең чиге-чамасы юк. Кайберләрендә башка милләт вәкилләре дә, катнашып, урыннар яулый ала. Өч мең сүздән торган хикәя өчен дә бер мең доллар, яки евро түлиләр. Һәм андый бәйгеләр атна саен булып тора. Шуларда катнашып, син аена бер тапкыр чын отсаң да, бер хикәяң өчен 50–60 мең сум аласың дигән сүз. Бу үзе үк стимул түгелмени? Ә бит андый бәйгеләр адым саен. Төрле жанрларда эшләүчеләр өчен, төрле темаларга багышлап уздырыла. Төрле яшьтәге каләм әһелләре белән эшлиләр. Сазаган язучыларның романнары өчен 100 мең доллар түли торган конкурслар да бар. Монысы инде безнеңчә 6 миллионга якын була. Һәм мине иң гаҗәпкә төшергәне – алар шулкадәр бүләк биреп тә, авторлык хокукларын язучыларның үзләрендә калдыралар. Бу конкурслар бездәге шикелле нинди дә нәшриятка, яки матбугат чарасына контент туплау өчен түгел, ә язучыларның матди хәлен чыннан да яхшырту һәм әдәбиятны күтәрү өчен эшләнә. Син урын яулыйсың һәм шул әсәреңне бастырып чыгарган өчен дә акча түлиләр. Без мондый хөрлекне күз алдына да китерә алмыйбыз.

Болардан тыш һәрбер автор газета-журналлар өчен төрле жанрларда кыска әсәрләр яза ала. Бәяләре төрлечә инде, тик син аена бер-ике генә язма чыгарсаң да, безнең журналистларның айлык хезмәт хакын аласың. Бит ярымлык юмореска өчен, мәсәлән, 500–1500 доллар түләүче басмалар бар. Бар түгел, күп. Әгәр мин инглиз, яки немец язучысы булсам, берничек тә ярлы була алмас идем.

Ярый, бер башлагач, әйтеп бетерим инде… Тегеконкурсларның берсендә мин дә катнаштым. Тәрҗемә ителгән хикәям беренче урын алды. Шуның өчен 1500 доллар түләделәр. Тик мин аны вакытында үз хисабыма күчереп рубльгә әйләндермәдем. Ә хәзер… Миңа ул акчаны чит ил бирми, хәтта чит ил бирсә дә, Россия каршы төшәр иде. Санкцияләр! Адәм көлкесе инде. Хәзер мин андый бәйгеләрдә берничек тә катнаша алмыйм, мин Россия кешесе буларак чикләүләргә дучар ителгәнмен. Шул рәвешле, санкцияләр иң беренче чиратта минем кесәгә сугә. Сәясәт диләр инде моны…

«Җир ярыла икән, ул иң беренче шагыйрь йөрәге аша үтә», – дигән сүз бар. Чынлап та шулай икән ул. Пандемия вакытында, мәсәлән, һәртөрле концертларны, тамашаларны тыеп тордылар. Миңа җырлар, театраль тамашалар өчен килә торган гонорар 3 мең сумга калды. Соңыннан да тиешле дәрәҗәгә күтәрелмәде ул. Шул рәвешле коронавирус иң беренче чиратта әдәбият һәм сәнгать әһелләре кесәсенә сукты. Нинди дер өлкәдә эшләүчеләргә һәртөрле компенсацияләр түләделәр. Ә әдәбият турында уйлап караучы да булмады. Әдәбиятның дәрәҗәсе нинди соң бездә, шулай булгач? Соңгы еллар сәясәте хәлыкны әдәбияттан, мәдәнияттән, хәтта үз милләтеннән биздерүгә кадәр барып җитте. Бу нинди максат белән эшләнгәндер, безгә караңгы инде.

Ә алга киткән чит илләрнең үз әдәбияты турында туктаусыз рәвештә хәстәрлек күрүе бер дә юктан гына түгел. Әйе, бу шактый зур хезмәт, көч һәм матди чыгымнар таләп итә. Ләкин нәтиҗәсе үзен аклый. Алар үз идеяләрен әдәбият аша, талантлы язучыларының популяр әсәрләре аша бөтен дөньяга тараталар. Дөньяны яулау әдәбият аша бара. Әгәр мин, әйтик, Рэй Брэдбери, Кормак Маккарти, Курт Воннегут кебек язучыларга мөкиббән киткәнмен икән, хәтта Америкаены да тулысынча дошман күрә алмыйм. Бу – аларның мине яулавы бит инде. Роман-хикәяләре артыннан шул әсәрләргә нигезләнгән кинофильмнар килә. Андагы тормыш, көнкүреш, фикер сөреше, кешеләр… Ниһаять, аларның мәдәнияте миңа да йога башлый. Шул рәвешле, әдәбият бернинди шау-шусыз гына тоташ илләрне, кыйтгаларны яулап алырга сәләтле. Монда бернинди армия дә, куркыныч кораллар да, аларга киткән чыгымнар да кирәкми. Куллана белгәндә, әдәбиятның тәэсир көче дә, дәрәҗәсе дә искиткеч зур аның.

Игътибар иткәнегез бармы икән… Дөньяда иң популяр язучылар кемнәр? Кайсы ил язучылары? Америка, Англия, Франция, Германия, Төркия… Иң көчле әдәбият та шуларда. Ни өчен шулай соң? Очраклы хәлме бу? Түгел, әлбәттә. Хәтта вәграк дәүләтләрнең талантлары да чит илгә, нигездә Америкага чыгып, танылу тапкан. Үзләрендә яшәп, үз телләрендә иҗат итсәләр, аларны бүген беркем дә белмәс иде. Нинди генә талант иясе булсалар да. Чөнки язучы, димәк, ул тудырган әдәбият та үз милләтеннән, үз дәүләтеннән аерылгысыз. Милләтнең дәрәҗәсе югары икән, әдәбиятның да абруе зур була. Күз алдына бастырырга җиңел булсын өчен менә мондый чагыштыру китерик. Әдәбият ул – корал, тәэсир итү коралы. Кылыч дип алыйк инде без аны. Бу очракта милләт аугир рәвешендә була. Ярлы, хәлсез, аягында көчкә басып торган аугир кулында нинди генә затлы кылыч булмасын, ул таза һәм гайрәтле дошманын җиңә алмый. Тегенең кулында затлы кылыч түгел, ә чүгендер чаба торган пычак булса да. Әгәр милләт көчле һәм гайрәтле икән, аның чүгендер пычагы кебек әдәбияты да зур һәм затлы булып тоела. Чөнки ул аның белән дөньяны яулый ала. Ә хәлсез милләтнең затлы кылыч шикелле әдәбияты да кечерәеп кала, эшкә яраксызга әйләнә. Чөнки милләт аның белән үз-үзен дә саклый алмый. Дөньяны яулау турында сүз дә юк инде…

Әдәбиятның дәрәҗәсе милләтнең саламәтлеге, зурлыгы һәм көчлелеге белән билгеләнә. Үз әдәбиятына икенчел итеп, кимсетебрәк караучы татарларны искә төшерсәм, күз алдыма: «Һи, безнең кылычның бер юне дә юк, аның белән хәтта җеп тә өзеп булмый бит», – дип зарланып басып торучы ике кулсыз адәм килеп баса. Кылыч, әлбәттә, затлы, тик ул үзлегеннән генә бернәрсә дә эшли алмый, ким дигәндә да аны кулына алырга кирәк, ә тегеадәмнең ике кулы да юк.

Мин төрле илләрнең популяр китаплары белән танышып баручы буларак, бер икеләнүсез әйтә алам: безнең әдәбият зур да, көчле дә. Бүгенгенән үк бөтен дөньяга танылырлык иҗатчыларыбыз бар. Артык күп түгел инде алар. Алай була да алмый. Ләкин булган кадәресе затлы, дәрәҗәле. Тик алар ике кулсыз адәм алдындагы булат кылыч сыман бер хәрәкәтсез, бер файдасыз булып ята бирә. Һәм язучылар тарафына каңгатьсез авыз ишетелә: «Һи-и, безнең әдәбият… Аның бит беркемгә дә кирәге юк…»

Әгәр халыкның тормыш кимәлен беләсең килә икән, бер генә нәрсәгә игътибар итү дә җитә: әдәбиятның дәрәҗәсе нинди?

Марат КӘБИРОВ

Юк аның белмәгән сәнгате, һөнәре…

9 АВГУСТ – БӨТЕНДӨНЬЯ КИТАП СӨЮЧЕЛӘР КӨНЕ

Кемдер, аның үз романтикасы бар дип, кәгазь китап актарырга яратса, кайсылары инде замана мөмкинлекләреннән файдаланып, электронына күчтә. Монда исә ничек укучы түгел, гомумән, укучыларның булуы мөһимрәктер. Без дә шул хакта сораштырдык.

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА, шагыйрә:
– Китап уку һәрвакыт, һәр заманда булган, бар, булачак. Мин балаларны да шулай тәрбиялим: китап укучы телевизор караучыдан алдарак барачак. Кызганыч, кәгазь матбугат турында андый фикердә түгелмен, әдәби журналлар, һөнәри махсус әдәбиятлар кала ул башка платформаларга күчеп, сакланып калачак. Актуальлек бик аксый – без локомотив тизлек заманында яшибез. Кәгазьгә алмашка сайт, электрон битләр килачәк, журналистлар төрле һөнәр, төрле төбәкләрдән торып эшләргә күчәргә тиеш. Миңа, мисал өчен, укыганда «кан төрлелеге» мөһим… Төрле караш, поляр фикерләр кирәк. Шуңа да цифрлы дөньяда эзләнү чоры бара.

Иң яраткан китап дип бүлә алмыйм. Уйга килгәннәрен генә атый алам. Эмили Бронтеның «Грозовой перевал», Эрих Мария Ремаркның «Триумфальная арка»сы, Патрик Зюскиндның «Парфюмер»ы, хәзер укыганы Робин Шарманың «Монах, который продал свой «Феррари», Ринат Вәлиуллин китаплары, Зөлфәт Хәкимнең «Ятимгә дә яз килә», соңгы арада чечен әдипләренең рус телендәге әсәрләрен укыйм: Муса Ахмадовның «Таулардан да биек» әсәре. Өстенлек – кәгазь китапка, бу канга сеңгән.

Балаларны китапка тартуның чарасы бер генә: әти-әнинең үзенең китап укуы.

Венера ШӘМСЕТДИНОВА, Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррир урынбасары:
– Татарстан китап нәшриятының сайты аша татар басма китапларын сату-алу сан һәм күләм ягыннан кимемәде. «Озон», «Вайлдбериз», «ЛитРес», «Казанэкспресс» кебек башка интернет-кибетләр аша да китаплар шулай ук сатыла. Сату-алу эшенә анализ нәтиҗәләре укучыда ихтыяҗ кимемәвен күрсәтә. Киресенчә, соңгы берничә ай эчендә активлык үсте диярлек мөмкин.

Татарстан китап нәшриятында басылган китапларның электрон версиясен дә әзерлибез. Укучыбыз, безнең яңа китапларыбыз турында анонсны күреп, аның башта электрон версиясен сорый. Басма китап әле кибетләргә килеп өлгермәгән да була. Сайтыбызның «Китапханә» бүлеге бар, анда бушлай электрон китапларны укырга мөмкин. Пандемия вакытында без тестлар, аудиоматериаллар белән баетылган электрон интерактив дәреслекләргә ихтыяҗ артуын күрдек. Бу китаплардан шулай ук бушлай файдаланырга мөмкин. Әлбәттә, татар китабының киләчәге бар, аңа ихтыяҗ сакланачак. Татарлар сан ягыннан шактый күп һәм алар бөтен дөнья буйлап сибелеп яши. Аларның күбесе балалар, оныклар туган телләрен белсен, өйрәнсен, туган тамырларын, милли гореф-гадәтләрен онытмасыннар дип тели. Шуңа күрә, бездә иң популяр китаплар – балалар китаплары, тарихи әдәбият, белешмә-сүзлекләр.

Сөмбелә ВӘЛИӘХМӘТОВА, алып баручы, нәфис сүз остасы:
– Китап укучылар бик күп бугай ул. Һәрхәлдә, минем танышларым арасында шактый. Прозадан иң яраткан китабым – Марат Кәбировның «Китап» романантиутопиясе. Бик тәэсирләнеп укыдым. Рэй Бредбериның «451 градус по Фаренгейту»га ишарәләр дә бар анда, автор бу турыда үзе дә кереш өлешә әйтеп үтә. Һәм шулай ук Аяз Гыйләҗевның «Йөгез, бер дога» романы. Татар әдәбиятыннан гына мисаллар китерәм, чөнки чит ил яки рус әдәбиятында менә монысы иң ошаганы дип сайлап ала алмыйм. Менә хәзерге акылым белән татар һәм рус классикасын яңадан укып чыгасым килә.

Поэзиядә иң яраткан китабым – Әнгам Атнабаевның шигырьләр җыентыгы. Аннан Илдар Юзеев, Гөлүсә Батталова, Эльмира Җәлилова шигырь җыентыклары. Болары – минем өстәл китаплары, дисәм дә, дөрес булыр. Туктап уйланырга кирәк булган чакларда шул шигырьләрне кабат-кабат укып, күңелемне бушатам.

Чит ил һәм рус әдәбиятында һәркем укырга тиешле китаплар исемлекләре төзиләр, интернет тулы төрле исемлекләр. Татар классикасы буенча да шундый исемлек булсын иде, дип телим. Чын мәгънәсендә лаеклы, дөнья әдәбияты белән көндәшлек итә алырлык әсәрләр исемлеге!

Миндә китап чире бар. Нинди төрәдер, ничек атала торгандыр инде, белмим. Электрон китапларны кабул итә алмадым, укый алмыйм мин аны. Нинди дер кыска хикәяләр генә укырга була әле, анысы да кул астында чын китап булмаганда. Ә кулга китап тотып укуны, аның исен, кәгазь кыштырдавын берни алыштыра алмый. Аннан соң китап минем үземнеке булырга тиеш, китапханәдән яки кемнәндер алып торып укырга яратмыйм, шулай ук үз китапларымны да кешегә биреп торуны сөймим.

Ильяс ФӘРХУЛЛИН, яшь музыкант:
– Китап укырга яратмый идем. Үсә төшкәч, мәхәббәт артты. Мәгънәле әсәрләр кешедә бик күп сәләтләр ача, сүз байлыгы туплана, рухи яктан байыйсың, әсәрнең геройлары тормышын «яшәп», тәҗрибә туплыйсың. Мин кәгазь китапны үз итәм. Яхшы язучылар күп, әмма күңелгә якыннары берничә генә. Хәзер китап укучыны сәер кеше итеп күрәләр. Армиядә чакта да китап турында онытмадым. Буш вакыт булуга, яңа әсәргә тотына идем. Мәҗлесләрдә чакта да кулымда – китап.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Бу – кызык!

► Нейропсихологлар сүзләренчә, китап уку стрессны 68 процентка киметә.
► ЮНЕСКО тәкъдиме буенча, 2021 елда Бөтендөнья китап башкаласы булып Тбилиси (Грузия) танылган. 2022 елда – Гвадалахара (Мексика).

ТАТАРЛЫКНЫ НИЧЕК САКЛАРГА?

Корылтайдан соң

Менә Бөтендөнья татар конгрессының (БТК) сигезенче корылтае да узып китте. Мәгълүм ки, һәр корылтай – «татарлыкны ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзләү, ике корылтай арасында башкарылган эшләргә хисап тоту ул. Шөкер, бу корылтайда хисап тоту белән әллә ни мавыкмадылар.

Хәер, эшләнелгән эшләр хакында алдагы көннәрдә сүз күп булды. Кабан күле буенда уздырылган «Печән базары» заманча татар дизайны һәм татар шәһәр мәдәнияте фестивалендә, Изге Болгар тарихи-архитектура музей-саклаулыгын гизгәндә, корылтай делегатлары һәм кунаклары секцияләргә бүленеп эшләгәндә дә бик күп чаралар искә алынды. Әйтик, «Тарихи шәхесләр һәм хәзерге заман татар дәүләт эшлеклеләре: милли горурлык тәрбияләү мәсьәләләре» дигән секция исеменнән үк күренгәнчә, бик мөһим бурычлар күтәрде. Әйе, тарихи хәтер – беренче чиратта милләтпәрвәрләребезне, тарихи шәхесләребезне белү ул. «Көн саен диярлек телевизорда күренүче әле ул күренекле кеше дигән сүз түгел. Берничә дистә ел узгач, кайбер кешеләр бөтенләй онытылырга да мөмкин. Дәүләткә хезмәт иткән шәхесләр милләт каһарманнары була алмый, милләт белән дәүләт төшенчәсе һәрвакыт туры килми», – диде бу уңайдан секция җитәкчесе, тарих фәннәре докторы, БТК каршында нәшер ителүче «Туган җир» журналы баш мөхәррире Дамир Исхаков. Казанда мәшһүр шәхесләребезгә багышлап ел саен «Кем ул милли каһарман, тарихи шәхес?» дигән конференцияләр үткәрә башларга тәкъдим итте ул. Секция эшендә катнашучыларның шәхес мәсьәләсендә фикере уртак: милләтебезнең алгарышына хезмәт иткән кеше генә шәхес була ала. Шәхеснең һәр вакыйга-хәлгә карата үз мөнәсәбәте, позициясе булырга тиеш.

Тарихи хәтер – бик зур төшенчә, бик күп мәгълүматны колачлый. Әнә язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова бик дөрес әйтә. «Без 15 февральне патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең һәм мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакировның туган көннәре дип билгеләп үтәбез икән, бу көнне, шәхес культы вакытында, татар дәүләте төзергә җыеналар дип, атып үтерелгән күренекле татар шәхесләре һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи һәм аның сигез фикердәшен дә искә алырга тиешбез». Корылтайда беренче булып чыгыш ясаган Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла да яшь буынга милли- патриотик тәрбия бирү зарурлыгын күтәрде. Гомумән алганда, ул милли узаң тәрбияләү проблемасын узәккә куйды.

– Хәлебез бик аяныч. Халкыбызның яртысыннан артыгы татарча белми. Милли мәгарифне югалта барабыз. Бүген татар теле һәм әдәбияты XI сыйныфта бөтенләй укытылмый, – дип, ул хосусый мәктәпләр ачарга, якшәмбе мәктәпләре эшчәнлеген киңрәк җәелдерергә, полилингваль мәктәпләр ачуны мәгариф эшчәнлегендә төп юнәлеш итәргә чакырды. Аның, сәяси милләт булыйк, аннан качып булмый, син аның белән шөгыльләнмәсәң, ул сине эзләп табып, үз чоңгылына бөтерел алып кереп китә, дигән фикере дә бик гыйбрәтле. Чоңгылларга кереп адашмас, вәйран булмас өчен, аек акыллы булуың, Тукай әйтмешли, мин әле кая барам, дип еш кына үз-үзеңә сорау биреп торуың мәслихәт.

Мәктәптә – тарих түгәрәкләре

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә балаларыбызда милли үзаң тәрбияләргә чакырды. Моның өчен язы буенда тарихи узаң тәрбияләргә, тәгаен алганда, Болгар тарихын укытырга, бу максатта җәй айларында Болгарда, төрле татар төбәкләреннән балаларны җыеп, җәйге лагерьлар оештырырга чакырды ул. Бик яхшы тәкъдим. Әлбәттә, Идел Болгарстаны тарихын укытырга кирәк дип әйтү – бабаларыбызның ислам дине кабул итү тарихын гына белсен дию түгел, Болгардан соң дәвам иткән татар дәүләтчелеге тарихын – Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын да өйрәнсен дигән сүз бу. Укучы балалар ил тарихын гына түгел, үзләре яшәгән шәһәр, авыл тарихын да белергә, укырга тиеш. Греция, Мисыр тарихын адәм баласы балигъ булгач та өйрәнә ала. Милләте, туган җире, гаиләсенең тарихын, үз шәҗәрәсен белмәгән кешенең чын мәгънәсендә патриот булып үсүе икеле.

«Бу җәһәттә кайбер районнарыбызда укучы балаларга Татарстан, район, авыл тарихын укытуның күркәм мисаллары бар. Мәктәп программасы моңа мөмкинлек бирә. Татарстан тарихын тарих түгәрәкләре рәвешендә дә укытып була. Кайбер мәктәпләребездә шулай эшлиләр дә. Моның өчен аерым укыту әсбапләре төзергә кирәк. Совет чорында андый ярдәмлекләр бар иде», – ди бу уңайдан Дамир Исхаков.

– Әлегәчә милли университет ача алмавыбыз, катнаш никахларның гаять нык артуы – татарлыкны югалта баруыбызның төп сәбәпләреннән. Бүген татарча сөйләшсәк, җырласак, шул җитә кебек. Милли, тарихи үзаң тәрбияли алмасак, эшебез хөрти, – дип, Казахстан татарлары һәм башкортлары конгрессы берләшмәсе рәисе урынбасары Гриф Хәйруллин яңгырлардан үрнәк алырга чакырды. Яхшы үрнәк бу. Әнә хәзерге вакытта илебездә яһүдләрнең ике хосусый университеты эшләп тора. Яһүдләр кем белән гаиләкорса да, балалары яһүд булып үсә. Без алардан киммени?!

Милли университет дигәннән. Бу җәһәттә байтак кына гуманитар галимнәребез хәзер, Татар дәүләт гуманитар университетын кабат терегеп, аны милли университет итеп эшләтергә тәкъдим итә. КФУның милли мәктәпләргә кадрлар әзерләп җиткерә алмавы хәзер беркемгә дә сер түгел.

Казахстанның халык рәссамы, мәшһүр милләттәшебез Камил Муллашев корылтай башланыр алдыннан башкалабызда, Мулланур Вахитов һәм Садри Максудидан башка сәясәтчеләребезгә һәйкәл юк, Камал театры каршындагы мәйданда гына да татарның бик күп мәшһүр кешеләрен танытучы сынннар куеп булыр иде, дип Казанда милли символларның бик аз булуыннан зарланган иде. Корылтай мөнбәреннән чыгыш ясаган Үзбәкстан татар-башкорт Аксакаллар шурасы рәисе Рим Гыйниятуллин бу мәсьәләне кабыргасы белән куйды. «Татар өчен бармакка бармак та сукмаган Бауманны ни өчен әле без һаман зурлыйбыз?» – дип, аның исемен йөрткән урамга Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев исемен бирергә чакырды ул. Үзебезне танырту, милли горурлыгыбызны уяту максатында, БТК исеменнән Татар көне, Татар гимны булдырырга да тәкъдим итте.

«Татарлыкны ничек саклап калырга?» дигән сорауга җавап эзләгәндә, 2020 елда уздырылган чираттан тыш корылтайны да искә алмасак, хата булыр иде. Анда бик мөһим документ – «Татарлар: гамәл стратегиясе» кабул ителде. Башкорт кардәшләребез дә шушында охшаш стратегия кабул итеп, аны тормышка ашыру юлларын билгеләгән дәүләт программасы эшләде. Безгә гамәлдә булган татар телен саклау һәм үстерү дәүләт программасын 2030 елга кадәр озайту белән чикләнмичә, әйтик, 2050 елга кадәр узебезне саклау юлларын билгеләргә иде. Тарих өчен 8–10 ел бик аз бит.

Рәшит МИНҺАҖ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Спорт

Бүре дә тук, сарык та исән

Яңартылган «Ак барс»ны тәүге тапкыр халыкка күрсәттеләр. Казан командасы, Әлмәт һәм Түбән Камага барып, «Нефтяник» белән «Нефтехимик»ны җиңеп кайтты. «Йолдыз» уенчылар алка сугу белән генә чикләнмичә, халык белән аралашты һәм тормышның башка ягын да күрде.

«Ак барс»ның Әлмәткә тәүге мәртәбә баруы түгел. Төп максат, бозга чыгып, «Нефтяник»ка каршы уйнау белән генә чикләнми. Сәфәрнең мәгънәсе тирәндәрәк. Билгеле булганча, Казан клубы «Татнефть» акчасына көн күрә. Ә нефтьне кем һәм ничек чыгара? Спортчыларга әнә шуны аңлатырга тырыштылар. «Ак барс»та алар өчен барлык шартлар булдырылган. Әлмәткә баргач исә егетләрне, башларына каска кидереп, гади «ПАЗик»ка утыртып, бораулау мәйданчыгына алып бардылар. Шулай итеп, аларның тормышны икенче яктан күрү мөмкинлеге булды. «Мондый очрашулар командага нефтьчеләрнең хезмәте ничек авыр икәнен күрү өчен кирәк. Аларга рәхмәт», – диде сәяхәт тәмамлангач команданың баш тренеры Олег Знарок.

Әлмәткә сәфәр нефть иснәү белән генә чикләнмәде. Команда уенчыларына җир эше дә эләкте. Бозга чыгар алдыннан аларны агач утыртырга алып бардылар. Кулларына көрәк һәм су тутырылган чиләк алып, хоккейчылар үзләреннән истәлек калдырды. Бу эшкә Олег Знарок белән команданың элеккеге баш тренеры, ә хәзер «Ак барс»та башкарма директорның хоккей эшләре буенча киңәшчесе итеп билгеләнгән Зиннәтулла Билалетдинов та кушылды. Алар Әлмәттә усак утыртып калдырды. Монысының мәгънәсе бар. Танылган ике тренер Казанга килгәч, аларның бер командага сыеша алмаячагын фаразлаучылар да булды. Әмма Знарок белән Билалетдиновның бозда да, аннан читтә дә тормыш тәҗрибәсе җитәрлек. Знарок үзе дә Билалетдиновны ишетергә әзер булуын яшерми. Бергә эшләячәкләрен Казанга килгәч үк белгән. Икесенең дә остаз булып эшләгәндә өчәр мәртәбә Гагарин Кубогы яулаганнары бар. Быел бергәләп отарга тырышачаклар. Әлегә исә икесенә бер усак утырттылар.

Шимбә көнне узган матчта «Ак барс» «Нефтяник»ны 6:1 исәбе белән тар-мар итте. Гадәттә, әзерлек матчлары күбрәк күнегү рәвешендә уза. Бу юлы исә алкалар да күп булды, хоккейчылар этеш-төртештән дә тайчанмады. «Һәр уенчының составка эләгү өчен үзен күрсәтәсе килә. Шуңа тырышып уйнаганнардыр, – диде Знарок. – Иптәшләрчә уен нәрсә дигән сүз ул? Аларга да, безгә дә әзерләнергә кирәк. Көндәш тә, без дә бу матчтан нәтиҗә чыгарабыз. Иптәшләрчә уенны сезон уртасында уздырырга була: нефть чыкканны күрәсең, тамашачы өчен 10:10 исәбенә хоккей уйныйсың, аннары буллитлар бәрәсең. Үзенә күрә Яңа ел тамашасы. Ә хәзер безгә сезонга әзерләнергә кирәк».

Баш тренерның сүзләрен уенчылар да дөрес аңлаган булып чыга. Александр Радулов беренче матчта ук ике алка кертте. Вадим Шипачев белән Станислав Галиев берәр пас бирделәр. Яңа уенчыларның «Ак барс»ның һөҗүменә соңгы елларда күрелмәгән мәгънә өстәгәне хәзердән үк күренә. Һәрхәлдә, күплектә уйнаганда ике алка керттеләр. Узган ел Казан командасы мондый мөмкинлектән файдалана алмый интекте. Команданы исә бозга Данис Зарипов алып чыкты: капитан вазыйфасын аңа тапшырдылар. Дмитрий Квартальнов заманында 41 яшьлек хоккейчы ара-тирә генә күренсә, Знарок аның тәҗрибәсен тулысынча файдаланырга тырыша. «Ул – безнең бердәнбер аксакалыбыз. Шуңа күрә капитан булырга лаек», – ди баш тренер.

Икенче матчны «Ак барс» Түбән Камада уздырды һәм 4:1 исәбе белән җирле «Нефтехимик» отты. Бу юлы Радулов белән Шипачев та, Зарипов белән Войнов та бозга чыкмадылар. Аның каравы башкаларга уйнау мөмкинлеге бирелде. «Безнең состав яхшы. Барысының да уйныйсы килә. Бүреләр – тук, ә сарыклар исән булсын өчен, үзгәрешләр булып торачак», – ди Знарок.

ak-bars.ru

ХЫЯЛСЫЗ ЯШӘДЕҢ НИ, ЯШӘМӘДЕҢ НИ...

Август – Салават ае

Быел зур сәхнәгә чыгуының беренче көннәреннән үк халыкны үзенә тарткан җырчы Салаватыбызның 34 нче сезоны. Өч дистә ел элек аны тамашачы ничек кабул итсә, хәзер дә шул ук: зал көн дә шыгрым тулы, алкышларның иге-чиге юк. Соңгы ике елда күрешкәндә: «Мин эшсез», – дип кул сузган Салават хәзер Аллаһы Тәгаләгә шөкер итә: «Без бит бергә, шунысы шатлык, җырларбыз без узганчы гомер».

Нияз Галиев

Гаилә хәленә килгәндә – 19 яшьлек уллары Рөстәм өйләнде. Беренче кодасы да Балык Бистәсе районыннан иде, хәзергесе дә.

Җырчыбызның быелгы тамашасында «Хыял» дигән тема үзәккә алынган һәм барлык чыгышлар да диярлек шушы тема тирәсендә бөтерелә. «Мин үзем – бик хыялый кеше, – ди Салават. – Хыялсыз тормыш тормыш түгел, хыялсыз яшәдең ни дә, яшәмәдең ни... Хыяллану җиңел, аны гамәлгә ашыру гына авыр, әлбәттә. Әмма теләк булганда, көч-куәт барында, хыял ул – чынбарлык. Яшермим, хыялга алданып яшим мин. Бу фикер узган сезондагы «Яшермим» дигән җырга да салынган. Ривал Хисмәтуллинның бу җырын җырлап туймадым әле, туймам да. Әлеге сезонда хәтта «Бер хыялым бар» дигән номинация дә бар».

Шушы уңайдан Салават хәтер яңарта: «Моннан байтак еллар элек мин жюрида утырганда Балтач районыннан килгән бер кызга киләчәге бик өметле, һичшиксез, җырчы булачак, дип тавыш биргән идем. Әмма өметем акланмады кебек. Ходайның рәхмәте, быел шул кыз элемтәгә чыкты. Вакыт узган саен еллар аны шактый сынаган: тормыш иптәшен җирләгән, игезәк балаларының берсенең сәламәтлеге мактанырлык түгел икән. «Салават абый, яшьлектәге хыялны тормышка ашырып булмасмы, – диде. – Чакырдым».

Үзенчәлекле тавыш иясе Резедә Әшрәпованы нәкъ менә сәхнә өчен яратылган диярсең, тамашачы бик җылы кабул итә, үзе исә, хыялым чынга ашты, дип куана.

Бөек җырчыларыбызны чакырып, аларны тамашачы хозурына тәкъдим итү дә – Салаватның күркәм, игелекле гамәле. Бу сезондагы тамашага Мәскәүдән Ренат Ибраһимов чакырулы була. «Ренат чакыруны бик җылы кабул итте, Казанымны, тамашачымны бик сагындым, диде, әмма нихәл итмәк кирәк, тормыш без дигәнчә генә түгел шул...» Сәхнәдән бер минутлык тынлык белән түгел, җырчының моңын тыңлап, башкару осталыгына сокланып искә алдылар һәм сезон дәвамында да, гастрольләрдә дә шулай булачак. Тамашаның беренче көнендә бер кочак чәчәк бәйләмнәре белән сәхнәгә Ренат Ибраһимовның хәләл җефете Светлана ханым да күтәрелде. Шунысы да мәгълүм булсын: Кукмара районының Туеш авылында Ренат Ибраһимовның әбисе Маһибәдәр (Ренат әбисенә «әннү» дип дәшә торган була), әнисе Асылбикә яшәгән йорт диварына истәлек тактасы элү ниятләнә. Ренатның балачагы, үсмер чагы узган нигез дә бу. Туешка ул бик еш кайтты. «Әннүләр мине эшкә өйрәтте, аларның хуҗалыгы шактый зурдан: сыер, кәҗә, сарык асрыйлар, ишегалды тулы каз, үрдәк, алма бакчалары бар, умарта тоталар. Мине исә чеп-чи татар авылы татарчага өйрәтте», – дип искә ала торган була.

...Концертларны алып баручы Ядкәр Хәбибуллинның исә үз хыялы – хыял. Ул концерт дәвамында «СКА» дип исемләнгән төркем туплау нияте белән янып-көеп, шуның хәстәрен күреп йөри, Салаватның көндәшләрен барлый. «СКА», ягъни Салаваттан куылган артистлар, Салаваттан качкан артистлар, Салаватка конкурент артистлар, Салаваттан көнләшкән артистлар, Салаватны күралмаучы артистлар, Салаватка килеп-киткән артистлар һәм башкалар, һәм башкалар. Ләкин Ядкәрнең кармагына эләгүчеләр, аны хуплаучылар гына табылмый. Тамашачы да, җырчы артистлар да Салаватка бары тик рәхмәтле.

Җырчы-композитор Фирзәр Мортазин шәрехләгәнчә, «Салаватның җыр сәнгатенә керткән өлешен бәяләп бетерерлек кенә түгел, кылган игелекләре үзенә, гаиләсенә, балаларына, оныкларына, туганнарына, якыннарына игелек булып кайтсын, 92 яше белән баручы әнисе Тәкълимә апага исәнлек-саулык, куанычлы, бәхетле көннәр телибез».

Кырык елдан артык Салават белән иҗади дуслыкта сәхнә тотучы баянчы-композитор Альфред Якшимбетов, шулай ук баянчы Илфат Шәехов бүлгәләнү, «СКА» яклы түгел. Бертуган абыйсының улы Айдар Фәтхетдинов та (быелгы сезонда ул да чыгыш ясый) туганлык җепләре нык, өзелмәслек булырга тиеш, дигән фикерен йөрәгә аша үткәреп җиткерә. Берничә көн рәттән сәхнәгә күтәрелүче җырчы-мөгаллим Миңгол Галиев өчен «СКА» – Салаваттан күтәрелгән артистлар.

Шәхсән Салават үзе көндәш төркем булдыруга һич каршы түгел. Конкурентлык ул үсешкә этәрә, дигән фикердә һәм булачак төркемгә ярдәм кулы сузарга да теләге бар, эшләми торган аппаратураларын, йөрми торган автобусын аларга бирергә әзер.

Өлкәннәр дә, яшьләр дә бер үк дәрәҗәдә үз итә җырчыбызны. Әле күптән түгел генә милли киемнәрдән бер әби сәхнәгә күтәрелде дә Салаватның колагына нәрсәдер пышылдады, җырчы исә елмаеелмая тыңлады да, аннан бик канәгать кыяфәттә «сер»не ачты. Салават әби-апаларга, үз итеп, «яшьти» дип дәшүчән. «Яшьти кунакка бүлмәсенә чакырды бит, – диде ул. Туксан яшен түгәрәкләп килүче әби исә Биектау районының Мүлмә авылыннан икән, Салават әллә чынлап та төшенмичә, әллә уен-көлкегә бору ниятеннән, Мүлмәне үзенчә аңлаган. Мондый кызык-мызыклар һәр концертта булып тора һәм тамашачы шаяруларны күңеленә якын кабул итә, сәхнә белән зал бер сулышта яши. Гомумән, концерт дәвамында шул сулыш саклана, ныгый бара.

«Элегрәк мин: «Ни өчен Салават концертлары ел саен Камал театрында үтә икән?» – дип үз-үземә сорау куя идем, – ди Гөлфирә Ихсанова, – 2018 елдан үзем шул театрда эшли башлагач, бик тиз төшендем: театрда аңлатып булмаслык рәхәтлек хөкем сөрә, бөтенләй икенче дөнья монда – килеп керүгә үк борчумәшәкатьләребез онытыла, күңел сафлана. Менә ни өчен Салават та камаллыларны үз итә икән! Залда тамашачыга хезмәт күрсәткәнлектән, абый-апалар, яшьләр белән дә элемтәдә булам: өлкән яшьтәге Нәгыймә апа, Салават концертларына мин дәвалану өчен киләм, дип шаккатырды. Чыны да шулай бит: аның җырлары мәгънәле, яшәргә сихәт, юаныч бирә, киләчәккә өмет уята, үсендерә, күңелгә май булып ята».

Шөкер, киләчәктә дә шулай була күрсен, башкалары кебек быелгы сезон концерты да – халкыбызның җанына дәрт өстәүче мул сулы шифалы чишмә.

Габделбәр РИЗВАНОВ

ЧҮЛМӘКЛӘР ЯСАУЧЫ ЭЛЬВИРА КОСАРЕВА:

«КҮҢЕЛНЕ ТЫНЫЧЛАНДЫРА ТОРГАН ҺӨНӘР БУ»

Балчыктан эшләнгән савытта ризык тәмлерәк була. Файдалы үзенчәлекләрен дә санап бетерерлек түгел. Баулыда яшәүче чүлмәк ясау остасы Эльвира Косарева әнә шулай ди. Табигый материалдан эшләнмәләр ясау серләрен ул безгә дә сөйләде.

Эльвира ханым белгечлеге буенча – сынлы сәнгать һәм сызым укытучысы. Егерме елдан артык Баулы мәктәбендә эшләгән. Аннары аны мәктәптән ял базасына, балалар пионер лагерена директор итеп чакырганнар. Өч ел шунда эшләп алган. Тик 2014 елда вазыйфасы кыскартуга эләккән.

– Шул елны Татарстан Икътисад министрлыгы һәм Казан федераль университеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган «Эшмәкәрлек фабрикасы» федераль белем бирү проекты эшли башлады. Әлеге проектта катнашу бәхете миңа да тәтеде. Монда безне үз эшеңне ачу серләренә өйрәттеләр һәм киләчәк бизнес проектын сайларга тәкъдим иттеләр. Шул вакытта миндә гадәти булмаган ял урыны – чүлмәк ясау эшенең һөнәрчелек остаханәсе булдыру идеясе туды. Үз проектымны яклап, сайлап алу этабын уздым һәм проектым Президент күргәзмәсенә тәкъдим ителде, – дип сөйләде Эльвира Косарева.

«Эшмәкәрлек фабрикасы»нда дәресләр белән беррәттән ул Уфада чүлмәк ясау курсларында укый башлый.

– Күп белем һәм тәҗрибә тупладым. Алар белән тизрәк уртаклашасым килде. Мәктәп диварларында бу идеяләрне тормышка ашырып булмый. Ә мин кешеләргә файдалы булырга теләдем. Ял базасында эшләү миңа шулкадәр ошады. Монда бит төрле кешеләр килә. Ә мәктәптә һаман бер үк составта эшлибез. Төрле характердагы, төрле карашлы кешеләр белән эшләү кызык иде миңа. Шөгылем хәзер инде яраткан эшемә әйләнде, – ди Эльвира ханым.

Балчыктан төрле савытлар ясау – аның өчен эш кенә түгел, ә чын мавыгу да. Гап-гади балчык аның кулларында әкренләп чын сәнгать әсәрләренә әверелә.

Эльвира Косареваның шәхси архивыннан

– Балчык ул – табигый материал. Балчык савытта пешерелгән ризык озак кына кайнар килеш саклана. Мин традицион башкару техникасында да, заманча техникада да эшлим. Традицион башкаруда ата-бабаларыбызның барлык традицияләре сакланып эшләнә. Элек бит заманча мичләр булмаган. Балчык, су һәм ут кына булган. Ә хәзер – муфель мичләре, чит илдән кергән балчык белән эшлибез. Бу – озак вакыт таләп итә торган шөгыль. Савытны әвәләгәндә бер мизгелне ычкындырсаң, берни дә эшләп булмый. Мин эшемдә яшим инде. Күңелне тынычландыра торган һөнәр бу, – ди оста.

Һөнәрчелек остаханәсен оештыру күп көч кенә түгел, зур чыгымнар да таләп итә. Шуңа күрә Эльвира «Татнефть» компаниясе оештырган грантлар конкурсында катнашырга була. Конкурста җиңү яулый һәм җиңгән акчага муфель миче һәм чүлмәк ясау җиһазы сатып ала. Ә инде 2018 елның июнендә Баулыда чүлмәк ясау остаханәсен ача. Эльвира ханым якын киләчәккә планнары белән дә уртаклашты:

– Бирегә әлегә төзелеш эшләре бара. Монда мин гаилә белән ял итү үзәге оештырырга телим. Территория кечкенә, аны киңәйтәчәкбез. Ретро интерьер сакланачак. Кешеләр монда тулы бер көнгә килеп, рәхәтләнеп ял итә алачак. Әле мунча комплексы, тагын бер остаханә төзелеп килә, – ди ул.

Эльвира ханым әйтүенчә, бирегә туристлар күп килә. Якын-тирә республикалардан, шәһәрләрдән гаиләләр белән күпләп йөриләр икән. Яшьләр өчен очрашулар да уздырам, ди ул.

– Башта фотосессия уздырабыз, чәй өстәле әзерлибез. Аннары һәр кеше үз эшләнмәсен ясый. Алар монда үз бeлдекләреннән генә әвәләп утырмыйлар, мин аларны чүлмәк ясау осталыгына өйрәтәм. Чүлмәк әйләнмәсе (җиһазы) фортепиано сыман. Фортепианода нота белмичә уйнап булмаган кебек, монда да кулны шомартмыйча, хәтта кечкенә генә бер чүлмәк тә ясап булмый, – ди оста.

Ләйсән САФИНА

ЧҮЛМӘК ЯСАУ БУЕНЧА ЭЛЬВИРА КОСАРЕВА КИҢӘШЛӘРЕ

1. Балчыкны бармаклар белән формага кертәбез.
2. Балчык әвәләнә, катырак халәткә керә башлый.
3. Әвәли-әвәли тиешле формага китерәбез. Хәрәкәтләр салмак, артык кискен булмаска тиеш.
4. Әзер савытны мичкә куябыз, уртача өч көн тотабыз. Мичтә ул акрынлап температура җыя.
5. Чүлмәкне сөт белән чылатабыз.
6. Шуннан соң тагын бер кат 300–350 градуслы мичкә куябыз. Икенче тапкыр мичтә яндыру процессын үткәч, чүлмәкләр ялтырап кала, савытның кырыйлары су үткәрми башлый. Мичтә яндырылган чакта һәр чүлмәк үзенә күрә бер төс ала.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Хөрмәтле Валерий Федорович!
«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән иң якын һәм газиз кешегез –
әниегезнең
вафат булуы сәбәпле, гаиләгезгә килгән авыр кайгыгызны уртаклашам. Бу авыр көннәрне кичерергә нык лы сабырлык бирсен.
«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте коллективы генераль директоры Наил Гобәйдуллин

Спас районы Иске Рәҗәп авылы Советы һәм районның якташлар җәмгыяте, сеңлесе
Лилиянең
вакытсыз вафат булуы сәбәпле, авылдашыбыз – республиканың җир һәм милек мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әнвәр улы Әһлиуллинның һәм барлык туганнарының олы кайгысын уртаклаша.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 314

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+